Республика Татарстан
Глава Монашевского сельского поселения
Менделеевского муниципального района
423643, Менделеевский район, с. Монашево,
ул. Школьная, д 19

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге Башлыгы
423643, Менделеевск районы,
Монашево авылы,
Мэктэп урамы, 19

тел./факс 8/85549/3-56-29, E-mail: Mon.Men@tatar.ru, http://mendeleevsk.tatarstan.ru/rus/monashevskoe-selskoe-poselenie.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.03.2024 г. № 6

2023 елның 30 ноябрендәге 9 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Илнәт авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 30 ноябрендәге 10 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Илнәт авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Илнәт торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1.2024 елның 6 апрелендә 17.00 сәг. ТР Менделеевск муниципаль районы Клуб урамы 6 йорт адресы буенча урнашкан Илнәт авыл мәдәният йортында 2023 елның 30 ноябрендәге 9 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Илнәт авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 30 ноябрендәге 10 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Илнәт авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Илнәт торак пунктында гражданнар җыенын билгеләргә.

2. 2023 елның 30 ноябрендәге 9 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Монашево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Илнәт авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 30 ноябрендәге 10 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегенең Илнәт авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр

кертү мәсьәләсенә сез ризамы” дигән сорауны гражданнар җыенында расларга һәм түбәндәгечә бәян итәргә:

«1) Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәл алу һәм урнаштыру, аның территориясен саклау һәм төзекләндерү);
2) тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (энергия саклаучы яктырткычларны һәм урам яктырту лампаларын алыштыру, Илнәт торак пунктында килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
3) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Илнәт торак пунктында янгын сүндерү машинасын тоту)?»

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны карар кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru « Монашево авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карар игълан ителү көненнән үз көченә керә.

Монашево авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Иосифов